| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***<br>***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***<br>***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |
|---|---|

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

25 июнь 2021 ел № 3-10

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәр Советы,

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Буа муниципаль районының Буа шәһәре Советының «Буа шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре турында» 2011елның 09 августындагы 2-9 номерлы (27.08.2017 ел № 2-23, 15.12.2017 ел №3-28, 14.09.2018 № 3-35, 29.12.2018 № 3-39, 29.03.2019 № 3-41, 11.06.2019 № 3-42, 23.07.2019 № 5-43, 14.11.2019 № 2-49, 27.12.2019 № 1-51, 30.07.2020 № 3-59, 18.03.2021-8 номерлы карарлар редакциясендә) карары белән расланган Буа шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Шәһәр төзелеше регламентлары» бүлеге 36 статьяның «Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.» «Ж1» тамгалы «Капиталь төзелеш объектларының иң чик күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары» таблицасын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

| Үлчәү берәмлекләре һәм параметрлары төрләре | | Күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте | |
|---|---|---|---|
| | | Аерым торучы гаилә йорты | Күп балалы йортта бер гаиләгә исәпләнгән торак берәмлек |
| **Җир кишәрлекләренең чик параметрлары** | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | 1000 | 1000 |
| Максималь мәйдан | кв.м | 5000 | 5000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Урам фронты буенда (керү юлы) минималь киңлек | м | 12 | 6 |
| **Җир кишәрлекләре чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары** Участок төзелешенең максималь проценты | % | 40,5 | 55 |
| Корылмаларның участокның алгы чигеннән минималь чигенү (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу сызыгы белән билгеләнмәгән очракта) | м | 3 | 3 |
| Участокның ян чикләреннән төзелмәләрнең минималь чигеннән чигенүләре | м | а) 1 - брандмауэр дивары мәҗбүри булганда; б) 3 – башка очракларда | а) 0 - күрше блокларга кушылган очракларда; б) 3 - башка очракларда |
| Участокның арткы чигеннән минималь чигенеш | м | 3 | 3 (әгәр башкасы төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгән булса) |
| Корылмаларның максималь биеклеге | м | 12 | 12 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 2,0* | 1,2* |

2) «Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.» 36 статьяның «Шәһәр төзелеше регламентлары» бүлегенең «Ж1» тамгалы «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гаражлар төзү һәм урнаштыру, хуҗалык корылмалары төзү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре» таблицасын таблицасын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

| Үлчәү берәмлекләре һәм параметрлары төрләре | Күчемсез милекне куллануның ярдәмче һәм шартлы pšхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте | | |
|---|---|---|---|
| | Бакчалар, яшелчә бакчалары (шәхси ярдәмче хуҗалык) | Шәхси гараңлар | Хуҗалык корылмалары |
| **Җир кишәрлекләренең чик параметрлары** | | | |
| Минималь мәйдан (кв.м) | 1000 | 10 | 10 |
| Максималь мәйдан (кв.м) | 5000 | 35 | 20 |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына да .http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа шәһәре башлыгы
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов